**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛƏЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

« 08 » февраля 2021 с. Тюлячи № 16

Аудиоязмаларны һəм презентация материалларын тəртипкə салу,
исəпкə алу һəм тапшыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2001 елның 29 гыйнварындагы 145-р боерыгын исəпкə алып, Телəче муниципаль районы Башкарма комитетының утырышлар залында трансляциялəнə торган аудиоязмаларны һəм презентация материалларын тəртипкə салу, исəпкə алу һəм тапшыру максатларында

1. Билгелəргə:

- аудиоязмалар һəм презентация материаллары (алга таба - мəгълүмати материаллар) Телəче муниципаль районы Башкарма комитеты хезмəткəре яисə киңəшмəне (утырышны) əзерлəү һəм уздыру өчен җаваплы Телəче муниципаль районының җирле үзидарə органнары хезмəткəренə (алга таба - җаваплы хезмəткəр) тапшырыла, шулай ук Телəче муниципаль районы Башкарма комитетының бердəм ведомствоара электрон документлар əйлəнеше системасы аша җибəрелгəн соратуы буенча, ул Телəче муниципаль районы Башкарма комитетының тиешле структур бүлекчəсе җитəкчесе белəн килештерелə;

- мəгълүмати материаллар җаваплы хезмəткəргə корпоратив электрон почта аша җибəрелə яисə электрон рəвештə тапшырыла;

- мəгълүмати материалларны саклау һəм алардан файдалану өчен җаваплы хезмəткəр шəхси җаваплылык тота.

2. Əлеге боерыкның үтəлешен контрольдə тотуны Телəче муниципаль районы Башкарма комитетының эшлəр идарəчесе И.Т. Һадиевка йөклəргə.

Җитəкче И.Х. Хəмидуллин